Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге
Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«21» ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толл калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Төрнәс авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм күтәртеп, төзәтеп чыгу;

- Төрнәс авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтү, товарлар сатып алу;

- Төрнәс авылында юллларны сезонлы карап тоту;

- Төрнәс авылында Җиңү паркын төзекләндерү;

- Төрнәс авылында су белән тәэмин итү чыганакларын (янгын гидрантлары өчен кое, скважиналарны лицензияләү) норматив хәлгә китерү;

- МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алу;

- Төрнәс авылында 3 данә күләмендә җәяүлеләр күперчегеп ремонтлау;

- Төрнәс авылында 3 данә кое бораулау.

Халык җыенында рәислек итүче: С.В. Белов

Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В. Белов